- ## Бәзәкә, кайда да безнең йөрәктә!

  Бәзәкәлеләр һәм кунаклар киң колач белән авылның 500 еллыгын бәйрәм иттеләр.
  (РәхиләМирзаянова)
-

  Тарихны кешеләр яза, диләр. Бәзәкә елъязмасы да моннан искәрмә түгел. Биредә гасырлар дәвамында хезмәт сөючән, кече ватаннарына тугрылыклы халык яши. Алар Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы зилзиләләрен лаеклы үттеләр, коллективлаштыру елларында колхоз төзеп, аның чәчәк атуына ирештеләр. Бәзәкәлеләр танылган якташлары, үзләре күләгәдә калып авылның үсешенә, күләмле бәйрәмнәрне оештыруга өлеш кертүче хәйриячеләр белән горурланалар.
-

  ### Яшә, чишмә, яшә!
- 500 еллыкны бәйрәм итү кысаларында «Изге чишмә»не ачу тантанасы булды. Ул җирлек халкын, күпсанлы кунакларны яңартылган кыяфәте, төзекләндерелгән территориясе белән гаҗәпләндерде.
  – Су чыганагын кабат торгызу турында сүз кыш көне үк кузгатылган иде, – диде сәламләү сүзендә район башлыгы Валерий Чершинцев. – Ул вакытта миңа Мингали Гайнетдинов мөрәҗәгать итте һәм төзелеш турында планнары белән бүлеште. Әлбәттә, мин каршы килмәдем. Чишмә суының сихәтләү үзлеге турында да ишеткәнем бар иде.
  Чыннан да, өлкән яшьтәгеләр бу табигый чыганакны «Фан чишмәсе» буларак беләләр. Суы күп авырулардан дәва булып тора дип сөйлиләр.
  – Һәр җәйдә минем әти якын-тирәдәге кырларда колхоз ашлыгын җыюда катнаша иде, – дип сөйли Бөек Ватан сугышы ветераны Зәйнак Әһлиев. – Мин аңа бик теләп булыштым. Төшке аш вакыты җиткәч, әти шул чишмәдән су алып килергә куша, аның энергиясе көне буена җитә дип әйтә иде.
  – Минем әби дә сихәтле чыганакка еш барды, – дип дәвам итә Сәйтәк клубының «Карендэшләр» фольклор ансамбле солисты Лилия Ефимова. – Озакка сузылган чирләрдән арыну өчен, чишмә янында төн кунарга кирәк дип сөйләгәннәре исемдә. Күпләр шулай эшлиләр иде.
  Проектның авторы, тумышы белән бәзәкәле Мингали Гыйләҗевич чишмәгә танылган хирург һәм онколог хөрмәтенә Рифкат Таҗиев исемен дә бирергә карар кылган.
  – Аның зур тәҗрибәсе, медицина өлкәсендә тирән белемнәре һәм алтын куллары миңа сәламәтлегемне торгызырга булышты, – диде М.Гайнетдинов.
  Рифкат Минһаҗевич үзе җавап сүзендә тыйнак булды:
  – Мин кешеләргә дан һәм шөһрәт өчен түгел, йөрәк кушуы буенча ярдәм итәм. Халыкта бу чыганак «Изге чишмә» дип аталса, яхшырак булыр.
  Ачылуга үзәк һәм Бәзәкә мәчетләренең дин әһелләре фатиха бирделәр һәм тәкъбир әйттеләр. Аннан соң зур булмаган концерт оештырылды. Тантаналы өлештән соң барлык теләүчеләр салкын судан авыз итә, аны савытларга ала алдылар.
-






Рифкать
чишмәсе




### Афәрин, егетләр!

Ат чабышлары программаның бизәге булды. Тамашачы егетләрнең күрсәтмә чыгышларын көчле алкышларга күмде. Чабышкыларда таң калдырырлык трюклар, төрле чорларның сугыш элементларын күрсәтү, атрибутлар – сөңге, кылычлар белән оста идарә итү, бәрелешләрдә тугры дуслар булган лачыннарны куллану беркемне дә битараф калдырмады. Егетләр белән беррәттән үз осталыкларын кызлар да тәкъдим иттеләр. Хуҗа-атлар һәм кунак атлары чабышлары, тарантасларда ярыш та азартлы булды.
«Ковбой» кушаматлы атты Сергей Метальников ярышты.
– Иң мөһиме – катнашу, – дип бүлеште чабышкының хуҗасы 87 яшьлек Хаҗи Шакиров. – «Ковбой»ны беренче тапкыр ярышка чыгардым, ул соңгы килсә дә, кәефем төшмәде. Сабан туйларныда ахырдан килгән атны аерым бүләкләгәннәр.
Чыннан да, чабышкы да, аның хуҗасы да, шулай ук җайдак та лаеклы призлар алдылар.






СТАРТ











- 
- 

**Котлаулар һәм бүләкләүләр**
**рәсми өлешне ачты.**

– Бүгенге бәйрәм Менделеевскиның 50 еллыгына тәңгәл килде һәм аның бер өлеше булды, – диде сәламләү сүзендә район башлыгы Валерий Чершинцев. – Бәзәкәлеләр тырышып эшли дә, чын күңелдән ял да итә беләләр. Җирлек заман белән бергә атлый.
Валерий Сергеевич «Изге чишмә»не төзекләндерүне башлап йөргән меценат Мингали Гайнетдиновка Рәхмәт хаты тапшырды. Мингали Гыйләҗевич шулай ук «Авыл алдындагы хезмәтләре өчен» дипломына лаек булды. Су чыганагын сафка бастыру белән шөгыльләнгән Дагыстан төзүчеләре истәлекле бүләкләр һәм милли баш киемнәре – түбәтәйләр алдылар. Алар хөрмәт йөзеннән Валерий Чершинцевка сарык тиресеннән тегелгән бүрек бүләк иттеләр.
Котлауларга
җирлек башлыгы Ринат Мөхәммәтҗанов, «Кама колхозы» ҖЧҖ директоры Азат Галимов кушылдылар.
Сабан туенда «Авылның мактаулы кешесе» исемен бирү күркәм традициягә әверелде. Быел Бәзәкә җирлеге башкарма комитетының депутатлык корпусы карары белән бу исемгә вафатыннан соң Марсель Гыймазетдинов лаек булды. Грамота һәм медальне шагыйрьнең апасы Римма Гыйльфановнага тапшырдылар.
Сувенирлар белән авылның хөрмәтле өлкән кешеләре, яңа гаилә корган яшь парлар, беренче сабыйлары туган гаиләләр билгеләнде. Бәзәкә мәчете мөхтәсибәте сугыш чоры балалары вәкилләренә бүләкләр әзерләде.
Азарт, спорт рухы, җиңүләр
Алга таба бәйрәмне халык һәм спорт уеннары дәвам итте. Мәйданчыкта волейбол баталияләре җәелдерелде: ңуҗалар, иске Гришкин, Карпов ис. химзавод командалары беренчелек пальмасы өчен ярыштылар. Нәтиҗәдә карповлылар җиңү яулады. Туры баганадан алынган әтәч Нижневартовскига китәр, мөгаен! Аны җитезлек белән Себер шәһәреннән Риф Сибгатуллин алып төште. Гер күтәрүдә Рамил Таҗиевка тиңнәр булмады. Милли көрәш яратучылар азарт белән спортчыларны күзәттеләр. Төп трофей – тәкә Ренас Кәлимуллинның җилкәсенә салынды. Ярышларның һәр төре үз җиңүчеләрен ачыклады.





### Йөрәкләрне җилкендер, Рифат!

Бәйрәм концерты Бәзәкә һәм Менделеевскиның үзешчән артистлары көче белән әзерләнде. Җыелганнар алдында үзенең иҗат төркеме белән татар җырчысы һәм бмор остасы Рифат Зарипов чыгыш ясады. Аның очкынлы шаяруы, дәртле җырлары көчле алкышларга күмелде. Ул күңелле композицияләр башкарганда кешеләр мәйдан уртасына биергә чыктылар. Теләүчеләр артист белән фотога төшә алды.

Балалар өчен аттракционнар, сәүдә рәтләре эшләде. 500 еллыкка багышланган чараларны Мәдәният йортында Алабугадан «Акцент» рок-төркеме катнашында кичке концерт һәм дискотека тәмамлады.





### «Искиткеч булды!»

Бәйрәмгә килүчеләр шулай диделәр. Кунаклар арасында без Бәзәкәдә туган булган тарих фәннәре кандидаты, доцент, гуманитар фәннәр өлкәсендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗәни исемендәге премиясе лауреаты Альта Мәхмүтованы очраттык. Нәкъ аның күләмле тырышлыгы, тикшеренүләре һәм тарихи документларны өйрәнүе нәтиҗәсендә авылның оешу датасы билгеле булды.

–Кәеф күтәренке, һава торышы кулай, танышларым белән күрештем, рәхәтләнеп бәйрәм карыйм, – дип бүлеште Альта Хаҗиевна.

– Һәрвакыт ат чабышларын зур дулкынлану белән күзәтәм, – дип сөйли хезмәт ветераны Шәргыя Ибәтуллина. – Бу акыллы җан ияләре үзләрен ничек тотарга белә. Сугыш елларында алар алыштыргысыз ярдәмчеләр булдылар, барлык авыр эшне башкардылар. Ә чабышка чыкканда, аларда азарт күзгә ташлана. Ике очракта да хуҗаларын сынатмаска тырышалар.

– Без Алабугадан килдек, – диләрт Зөһрә һәм Равил Сәлаховлар. – Күргәннәрдән таң калдык! Оештыру югары дәрәҗәдә, бөтен ваклыкларына кадәр уйланылган. Рәхәтләнеп концерт карадык, тәмле шашлык ашадык, сувенир продукциясе алдык, һәм, ышанмассыз, бик күп танышларыбызны очраттык.















